ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
**РУССКО-ОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Профсоюзная, дом 7а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422642, Рус Әшнәге,
Профсоюз урамы, 7а нче йорт

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, e-mail:Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Рус Әшнәге авылы №3 от 29.04.2021г

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл  җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча Административ регламентны раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар Кодексы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл  җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл  җирлеге Башкарма комитеты  КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл  җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү буенча муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча Административ регламентны расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл  җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,Рус Әшнәге авылы,Мәктәп урамы 9а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетының
20 21 елның 29 апрелендә
3номерлы карары белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү буенча муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча Административ регламент**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Административ регламент Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә (алга таба текст буенча – җирлек) Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гражданнар тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тикшерүне оештыру һәм уздыруны гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәүгә муниципаль контроль Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны турыдан-туры җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге:

1993 елның 12 декабрендә бөтенхалык тавыш бирүе белән кабул ителгән Россия Федерациясе Конституциясе;

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон;

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы.

Норматив хокукый актлар исемлеге тулы түгел.

1.4. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль предметы булып юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гражданнар тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен тикшерү, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге чикләрендә урнашкан территорияләрне төзекләндерүгә

карата күрсәтелгән таләпләрне бозуларны профилактикалау (кисәтү) чараларын оештыру һәм үткәрү тора.

1.5. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары:

1.5.1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы органның вәкаләтле заты тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар адресына документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру таләбе белән дәлилләнгән гарызнамә җибәрергә (муниципаль контроль органы карамагындагы документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса яки әлеге мәгълүматлар муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәгән очракта);

юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларны (башкарыла торган эшләрне, тәкъдим ителүче хезмәтләрне), территорияләрдәге биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне карау, өйрәнү, үлчәү, фото - һәм видеофиксацияләүгә;

муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу һәм (яки) бирелгән күрсәтмәнең үтәлмәве факты буенча аңлатмалар алырга.

1.5.2. Тикшерү барышында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта муниципаль контроль органы:

- ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, юридик затка, индивидуаль эшкуарга, гражданга (алга таба – муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затка) һәм (яисә) кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүне булдырмау чаралары, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтүгә, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларга ия документларга зыян китерүне булдырмау буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмә бирә;

- ачыкланган бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлеген тәэмин итүгә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтүгә зыян китерүне булдырмау буенча чаралар, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны булдырган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрә.

1.5.3. Тикшерү үткәргәндә муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

2) тикшерү үткәрелә торган юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, Россия Федерациясе законнарын үтәргә;

3) тикшерүне анық билгеләнешенә ярашлы рәвештә җирлек администрациясе күрсәтмәсе нигезендә үткәрергә;

4) тикшерүне фәкать хезмәт бурычларын үтәгән вакытта гына, урынга килеп (күчмә) тикшерүне җирлек администрациясе күрсәтмәсенең күчермәсен күрсәткәндә генә һәм 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендәге 5 өлешендә каралган очракта тикшерү уздыруны килештерү турындагы документның күчермәләрен күрсәткәндә генә үткәрергә;

5) тикшерү үткәрелә торган затларга яисә аларның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашуга һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

6) тикшерү уздырыла торган затка, аның вәкаләтле вәкиленә, катнашучыларга тикшерү үткәргәндә тикшерү предметына караган мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;

7) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларны, аларның вәкаләтле вәкилләрен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларны, аларның вәкаләтле вәкилләрен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, күрсәтелгән чараларның хокук бозулар авырлыгына туры килүен, аларның кешеләр тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү өчен потенциаль куркынычлылыгына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

10) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар тарафыннан шикаять белдерелгәндә, аның вәкаләтле вәкиленә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз гамәлләренең нигезле булуын исбатларга;

11) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тикшерү үткәрү срокларын үтәргә;

12) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлардан, аның вәкаләтле вәкиленнән Россия Федерациясе законнарында каралмаган документлар һәм башка мәгълүматлар таләп итмәскә;

13) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларның, аның вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча урынга барып (күчмә) тикшерүне үткәрү алдыннан аларны аның нигезендә тикшерү уздырыла торган әлеге Административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) журнал юридик затта, индивидуаль эшкуарда булган очракта, тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү турында язып куюны гамәлгә ашырырга.

1.6. Тикшерү уздырганда муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хаклы түгел:

1) таләпләр муниципаль контроль органы вәкаләтләренә кермәсә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең һәм мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләренең үтәлешен, шулай ук аларны куллану мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

3) мәҗбүри таләпләрнең һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган (игълан ителмәгән) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә. ;

4) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган зат, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлаштырылган яисә планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 өлеше 2 пунктының "б" пунктчасында каралган нигез буенча мондый тикшерүне үткәрү очрагыннан гайре, шулай ук җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләренә һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларга тиешенчә хәбәр итү очракларында җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерүдән тыш;

5) әгәр тикшерү объектлары булып тормаса яки тикшерү предметына карамаса, документларны, мәгълүмат, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын бирүне таләп итәргә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алырга;

6) күрсәтелгән үрнәкләрне сайлап алу турында беркетмәләр тутырмыйча, тикшерүләр, сынаулар, үлчәүләр үткәрү өчен продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын, билгеләнгән форма буенча һәм нормадан артып киткән милли стандартлар, үрнәкләрне сайлап алу кагыйдәләре, аларны тикшерү, сынаулар, үлчәүләр, техник регламентлар белән билгеләнгән яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документлар һәм кагыйдәләр һәм тикшеренүләр, сынаулар, үлчәү методлары белән билгеләнгән күләмдә пробалар алырга;

7) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт урыныныкы, закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматны, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан гайре, таратырга;

8) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларга, аның вәкаләтле вәкиленә күрсәтмәләр бирүне яисә алар исәбеннән контроль чараларын уздыру турында тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашырырга;

9) муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлардан, аның вәкаләтле вәкиленнән документлар һәм (яисә) мәгълүматны, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагында булган рөхсәт бирү документларын да кертеп тапшыруны таләп итәргә;

10)муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлардан, аның вәкаләтле вәкиленнән документларны, мәгълүматны тикшерү үткәрелә башлаган датага кадәр таләп итәргә. Муниципаль контроль органы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә кабул ителгәннән соң ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны соратырга хокуклы.

1.7. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль чаралары гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары

1.7.1.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар тикшерү уздырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органыннан, муниципаль контроль органыннан, аларның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына керә торган мәгълүматны алырга, аны бирү Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда, Нигезләмәдә һәм әлеге Административ регламентта каралган;

3) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документларны һәм (яки) мәгълүматны Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына үз инициативасы буенча тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, алар белән килешү яки алар белән килешмәү, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән танышу турында күрсәтергә;

6) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә тикшерү үткәргәндә юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын бозуга китергән дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирергә;

7) Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилне яисә эшкуарлар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы

Президенты каршындагы вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә.

1.7.2.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар, аларның вәкаләтле вәкилләре тиеш:

җитәкчеләр, башка вазыйфаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре катнашуын тәэмин итәргә; индивидуаль эшкуарлар үзләре катнашырга яисә мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештыру һәм уздыру өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең анда булуын тәэмин итәргә тиеш;

документлар буенча тикшерү уздырганда дәлилләнгән гарызнамә алынган көннән алып ун эш көне эчендә муниципаль контроль органына гарызнамәдә күрсәтелгән документларны җибәрергә;

күчмә тикшерү уздыра торган муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи затына күчмә тикшерүгә кадәр документлар буенча тикшерү үткәрелмәгән очракта күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә, шулай ук урынга барып тикшерү уздыручыларның һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган территориядәге биналарга, төзелмә, корылма, бүлмәләргә, эшчәнлекне гамәлгә ашырганда юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан кулланылучы андагы җиһазларга, охшаш объектларга, транспорт чараларына һәм алар ташый торган товарларга керү (күрү) мөмкинлеген тәэмин итәргә.

2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны бозуга юл куйган юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, индивидуаль эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре тикшерүне үткәрүгә нигезсез рәвештә комачаулый торган, тикшерүне үткәрүдән читләшүче һәм (яисә) билгеләнгән срокта мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен үтәми торган затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

1.8.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәләре.

Юридик затны, индивидуаль эшкуарны, гражданны тикшерү актын төзү муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәсе булып тора.

Тикшерү акты ике нөсхәдә тикшерү тәмамлаганнан соң ук рәсмиләштерелә, шуларның берсе кушымталарның күчермәләре белән муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затка, аның вәкаләтле вәкиленә танышу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында кул куйдырып раслама белән тапшырыла.

Физик зат, җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерүче затның акт белән танышу турында яки тикшерү акты белән танышуны кире кагу хакында раслама бирүдән (имза салудан) баш тартуы очрагында акт заказлы почта юлламасы белән тапшырылу турындагы хәбәрнамә белән җибәрелә, хәбәрнамә муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү актын төзү срогы контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаска тиеш һәм ул муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларга, аның вәкаләтле вәкиленә раслама алып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта юлламасы белән һәм (яки) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелә торган затның муниципаль контроль кысаларында электрон формада хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруга ризалыгы булганда), күрсәтелгән документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә. Мондый чакта күрсәтелгән документны алу турында хәбәрнамә һәм (яисә) бүтән раслау муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә.

1.9. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру һәм тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматларның тулы исемлеге

1.9.1.Тикшерү барышында тикшерелүче юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән таләп ителә торган кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматларның тулы исемлеге.

Тикшерү барышында вазыйфаи затлар юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән шәхсән түбәндәгеләрне соратып алалар, гарызнамәгә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның мөһер белән таныкланган күчермәсе теркәлә:

- оештыру (гамәлгә кую) документлары;

- күчемсез милек объектына хокук билгеле торган документлар;

1.9.2. Ведомствоара исемлек нигезендә башка җирле үзидарә органнарыннан яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тикшерү барышында соратыла һәм алына торган документларның һәм (яки) мәгълүматларның тулы исемлеге.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тикшерү барышында соратыла һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүмат:

1) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;

2) индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар.

## 2.Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль контроль органы түбәндәге адрес буенча урнашкан:____________________

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат (хәбәр) бирү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге адрес буенча башкарыла:_____________

телефон: __24643

эш графигы: ________________

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән тәгаенләнә.

Муниципаль районның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтының адресы (алга таба – “Интернет” челтәре): (http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru/).

Муниципаль хезмәт турында, шулай ук Башкарма комитетның эш графигы һәм урнашкан урыны турында мәгълүмат түбәндәгеләрдән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр (мөрәҗәгать итүчеләр) белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны эченә алган Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

2) муниципаль районның Интернет челтәрендәге www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. рәсми сайты ярдәмендә;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatar.ru/ дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында (алга таба – Республика порталы);

4) http:// www.gosuslugi.ru/ Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында (алга таба – Бердәм портал).

5)Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазь йөрткечтә, электрон почта буенча электрон рәвештә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләре турында консультация бирү мәсьәләләре буенча гражданнарны, шәхси эшмәкәрләрне (аларның вәкилләрен), юридик затлар вәкилләрен шәхсән кабул итү “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оештырыла һәм гамәлгә ашырыла.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләре турында мөрәҗәгать итүченең язма мөрәҗәгатьләре, җавапны әзерләү өчен кирәкле вакытны исәпкә алып, хезмәткәрләр тарафыннан язма мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 30 көннән дә артмаган срокта карала.

Электрон документ рәвешендә кергән консультация өчен мөрәҗәгать “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә мәҗбүри рәвештә күрсәтелә: фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булган очракта),

электрон почта адресы, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, һәм почта адресы, әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса. Мөрәҗәгать итүче мондый мөрәҗәгатькә электрон рәвештә кирәкле документларны һәм материалларны кушымта итеп теркәргә яки күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ачык мәгълүмат бирү түбәндәге мәгълүматны урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында;

гаммәви мәгълүмат чараларында;

гражданнар күпләп җыела торган урыннардагы мәгълүмат стендларында;

Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында, җирлек бүлегендә, урнашу урыны, эш графигы, почта адресы, электрон почта адресы, муниципаль контроль органының белешмә телефоннары, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар исемлеге, административ регламент тексты, хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына карата шикаять белдерү тәртибе урнаштырыла.

2.2.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль түләүсез нигездә башкарыла.

2.3.Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру сроклары.

Тикшерү үткәрү вакыты авыл җирлеге хакимиятенең тикшерү үткәрү турындагы карарында (боерыгында) күрсәтелә.

Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата тикшерүләр үткәрү вакыты егерме эш көненнән дә артмаска тиеш.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата планлы күчмә тикшерүне үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен елына унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарурилыгы белән бәйле аерым очракларда күчмә тикшерүне үткәрү вакыты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Җитәкчесе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма егерме эш көненнән дә артык түгел, кече предприятиеләргә карата – илле сәгатьтән артык түгел, микропредприятиеләргә – унбиш сәгатьтән дә артык түгел. Планлы күчмә тикшерүләр үткәргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яисә) мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерү үткәрү Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка, әмма ун эш көненнән дә артыкка түгел, туктатылырга мөмкин. Тикшерүне үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү уздыруны туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда территориядә, биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда, бүлмәләрдә, кече эшкуарлык субъектының башка объектларында муниципаль контроль органының күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре туктатып торыла.

**3.Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары**

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

- тикшерү үткәрү турында карар әзерләү һәм кабул итү;
- тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә җибәрү;
- тикшерүне үткәрү;
- тикшерү акты төзү;
- тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу очракларына карата чаралар күрү;

Тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару, аңа тиешле мәгълүмат кертү һәм аны ачу дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Барлык административ процедуралар да законнар нигезендә тиешле вәкаләтләр бирелгән муниципаль контроль органы тарафыннан башкарыла.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль түбәндәге эзлеклелектә гамәлгә ашырыла:

3.1. Тикшерү үткәрү турында карар әзерләү һәм кабул итү

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль планлы һәм планнан тыш тикшерүләр рәвешендә

башкарыла.

3.1.1.Әлеге процедураны башлау өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планында күрсәтелгән тикшерүне үткәрү датасының килеп җитүе;

2) Административ регламентның 3.1.2.пунктында күрсәтелгән нигезләр.

Планлы тикшерүләр җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган еллык планлы тикшерүләр планы нигезендә үткәрелә.

Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата ел саен планлы тикшерүләр планы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнә һәм прокуратура белән килештерелә.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын әзерләү, аны прокуратура органнарына тапшыру һәм килештерү тәртибе, шулай ук планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планының үрнәк рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан тәгаенләнә.

Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата еллык тикшерү планы кызыксынган затларга аны җирлек Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән җиткерелә.

3.1.2.Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора:

1)юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы тәмамлануы;

2) авыл җирлеге Башкарма комитетына юридик заттан яки индивидуаль эшкуардан эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыруга хокукый статус, махсус рөхсәтнамә (лицензия) бирү яки башка юридик әһәмиятле гамәлләрне башкаруга рөхсәтнамә (килештерү) бирү турында гариза керүе, әгәр юридик затның, индивидуаль эшкуарның тиешле планнан тыш тикшерүен үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәтнамә (лицензия) бирү, рөхсәтнамә (килештерү) бирү кагыйдәләрендә каралган булса;

3) юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлексез контрольдә тоту чараларының нәтиҗәләрен анализлау, дәүләт контроле (күзәтчелек) органнарына, муниципаль контроль органнарына кергән гражданнар, шул исәптән юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында кергән мәгълүматны карау яисә алдан тикшерү йомгаклары буенча җирлек Башкарма комитетының вазыйфаи затының дәлилле тәкъдиме:

а) кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү куркынычы, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә куркыныч янау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зарар салу, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү.

4) Прокурорның законнар үтәлешен күзәтү кысаларында прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә.

Әлеге Административ регламентның 3 бүлегендәге 3.1.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура белән килештерелгәннән соң үткәрелергә мөмкин.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия

Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян салу, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны ачыклау торса, кичектергесез чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә мондый хокук бозулар башкарылган вакытта, муниципаль контроль органы, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсенең 6 һәм 7 өлешләрендә каралган документларны прокуратура органнарына җибәрү юлы белән тикшерү чараларын үткәрү турында кичекмәстән прокуратура, авыл җирлеге органнарына хәбәр итеп, егерме дүрт сәгать эчендә планнан тыш тикшерү үткәрүгә керешергә хокуклы. Бу очракта прокурор яки аның урынбасары тиешле документлар кергән көнне планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул итә.

Юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян килгән яисә китерелгән очракта, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән яисә килеп чыгарга мөмкин булганда, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрелә башлау турында алдан хәбәрнамә ирештерү таләп ителми.

Гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда таләпләрнең үтәлешен планнан тыш тикшерүләр прокуратура белән килешенмичә гамәлгә ашырыла.

3.2. Тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә әзерләү һәм җибәрү

3.2.1. Планлы тикшерү үткәрү турында контроль гамәлгә ашырыла торган затка, аны үткәрү башланганчыга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, планлы тикшерүне үткәрү башлануы турында авыл җирлеге хакимияте боерыгының күчермәсен тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы юллама белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документ ярдәмендә һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон почта адресы буенча җибәрү юлы белән, әгәр мондый адрес юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрында булса яисә элек юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан муниципаль контроль органына яки башка мөмкин булган ысул белән тәкъдим ителгән булса, муниципаль контроль органы тарафыннан хәбәр ителә.

3.2.2. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында, әлеге регламентның 3 бүлегенең 3.1.2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән гайре, юридик затка, индивидуаль эшкуарга, гражданга аны үткәрү башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала муниципаль контроль органы тарафыннан мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр ителә.

Административ процедураны үтәү вакыты – 1 сәгать.

3.3. Тикшерүне үткәрү

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль предметы булып юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гражданнар тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерү тора.

Тикшерү җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенең тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә үткәрелә.

Тикшерү тикшерү үткәрү турында карарда күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелә ала.

Тикшерүләр документлар буенча тикшерү һәм (яисә) күчмә тикшерү рәвешендә уздырыла.

Документлар буенча тикшерү (план буенча да, планнан тыш та) муниципаль контроль органы урнашкан урында уздырыла.

Муниципаль контроль органы карамагындагы документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырган очракта яки бу мәгълүматлар төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларның муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, муниципаль контроль органы мондый затларга, документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны

тапшыруны таләп итеп, дәлилләнгән гарызнамә җибәрә.

Гарызнамәгә җирлек администрациясенең документлар тикшерүен үткәрү турындагы боерыгының мөһер белән таныкланган күчермәсе теркәлә.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган зат дәлилләнгән гарызнамә алган көннән алып ун эш көне эчендә муниципаль контроль органына гарызнамәдә күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (ул булса) һәм индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең, юридик затның башка вазыйфаи затының имзасы белән белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, индивидуаль эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Юридик зат, индивидуаль эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны электрон документлар рәвешендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшырырга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, муниципаль контроль органына тапшырыла торган документларның күчермәләренең нотариаль таныкланган булуын таләп итү рөхсәт ителми.

Документар тикшерү барышында тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар яисә әлеге документлардагы мәгълүматларның муниципаль контроль органында булган документлардагы мәгълүматларга һәм (яки) төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында алынган документларга туры килмәве ачыкланган очракта бу хакта төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үткәрелә торган затка ун эш көне эчендә язма рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыруны таләп итеп мәгълүмат (хәбәр) җибәрелә.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль уздырыла торган зат, муниципаль контроль органына тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата аңлатмаларны һәм (яисә) әлеге мәгълүматларның туры килмәвенә карата аңлатма бирә яисә аның вәкаләтле вәкиле муниципаль контроль органына элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган өстәмә документлар тапшырырга хокуклы.

Күчмә тикшерү (планлысы да һәм планнан тышы да) юридик затның урнашу урыны, индивидуаль эшкуар эшчәнлеге һәм (яки) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча, гражданин карамагында булган мөлкәтнең урнашу урыны буенча үткәрелә. Административ процедураны үтәү вакыты авыл җирлеге администрациясенең тикшерү үткәрү турындагы боерыгында күрсәтелә.

Документлар буенча тикшерү уздыра торган муниципаль контроль органы җитәкченең яки юридик затның башка вазыйфаи затының, индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны карарга тиеш. Күрсәтелгән аңлатмаларны һәм документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыкласа, муниципаль контроль органы күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы. Күчмә тикшерүне уздырганда юридик заттан, индивидуаль эшкуардан документар тикшерү барышында алар тарафыннан тапшырылган документлар һәм (яки) мәгълүматны таләп итү тыела. Күчмә тикшерү (планлысы да һәм планнан тышы да) юридик затның урнашу урыны, индивидуаль эшкуар эшчәнлеге һәм (яки) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча, гражданин карамагында булган мөлкәтнең урнашу урыны буенча үткәрелә.

3.4. Тикшерү актын төзү.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты төзелә.

Тикшерү актына продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын сайлап алу беркетмәләре, үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертиза беркетмәләре яки бәяләмәләре, юридик зат һәм индивидуаль эшкуарның муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләренең аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.

Тикшерү акты ике нөсхәдә тикшерү тәгәлләнгән соң ук рәсмиләштерелә, шуларның берсе кушымталарның күчермәләре белән муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затка,

җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә аларның вәкаләтле вәкилләренә акт белән танышу турында яки тикшерү акты белән танышудан баш тарту хакында имза салдырып раслама белән тапшырыла.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче затның акт белән танышу турында яки тикшерү акты белән танышуны кире кагу хакында раслама бирүдән баш тартуы очрагында акт заказлы почта юлламасы белән тапшырылу турындагы хәбәрнамә белән җибәрелә, хәбәрнамә муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетелә.

Тикшерелә торган затның муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыруга ризалыгы булганда, тикшерү акты муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затка яисә аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

Дәүләт, коммерция, хезмәт урынынықы, башка серләрне тәшкил иткән тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

Муниципаль контроль органының вазыйфаи заты уздырылган тикшерү турында язманы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барырга хокуклы булган тикшерүләрне исәпкә алу журналында язып куеп гамәлгә ашыра.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында тиешле язма ясала.

Тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән килешмәгән яки ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, юридик зат, индивидуаль эшкуар, гражданин тикшерү актын алган көннән алып унбиш көн эчендә тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата каршы килүен (ризасызлыгын) муниципаль контроль органына язма рәвештә тапшырырга хаклы.

Шул ук вакытта юридик зат, индивидуаль эшкуар, гражданин мондый каршылыкларга әлеге каршылыкларның нигезлелеген раслый торган документларны яисә аларның расланган күчермәләрен яки килештерелгән вакытта аларны муниципаль контроль органына тапшырырга хокуклы.

Административ процедураны үтәү вакыты – тикшерү тәмамланган көн. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срокта төзелә һәм ул җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә кул куйдырып раслама нигезендә тапшырыла яисә заказлы почта юлламасы белән тапшырылу турындагы хәбәрнамә белән юллана һәм (яки) актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яки муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруга ризалыгы булганда), күрсәтелгән документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә.

Бу чакта күрсәтелгән документны тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яисә) алуны башка раслау дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы яисә муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

3.5. Тикшерү яки планлы (рейд) карау, тикшеренү үткәргәндә ачыкланган бозу очракларына карата чаралар күрү.

Муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны тикшерү уздырганда бозулар ачыкланган очракта тикшерүне уздыручы вәкаләтле вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләре чикләрендә бурычлы:

1) юридик затка, индивидуаль эшкуарга ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын күрсәтеп һәм (яки) кешеләрнең тормышына,

сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга зыян салуны, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтүгә, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны күрү хакында күрсәтмә бирергә;

2) ачыкланган бозуларны бетерүне, аларны кисәтү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зыян китерүне булдырмау, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын да күрергә;

Тикшерү барышында юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, индивидуаль эшкуарның эшчәнлеге, алар тарафыннан биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне, җиһазларны, охшаш объектларны, транспорт чараларын эксплуатацияләүнең, алар тарафыннан җитештерелә торган һәм сатыла торган товарларның (башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләрнең) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүгә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә зыян китерүнең турыдан-туры куркынычы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне тудырулары ачыкланган очракта яки андый зыян китерелгәндә муниципаль контроль органы зыян китерүне булдырмый калу яисә аны китерүне туктату буенча юридик затның, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә аның филиалы, вәкиллекләре, структур бүлекчәсе, индивидуаль эшкуар эшчәнлеген вакытлыча тыюга кадәр, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч тудыручы продукцияне әйләнештән алып гражданнарга, шулай ук башка юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга зыян китерү куркынычы булу һәм аны булдырмау ысуллары турында теләсә нинди үтемле ысул белән җиткерү буенча кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

Күрсәтмә күрсәтмәдә билгеләнгән срокта муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш. Элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы чыгу әлеге Административ регламентта каралган тәртиптә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора.

Планлы (рейд) караулар, тикшеренүләр уздырганда, мәҗбүри таләпләр һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты үз компетенциясе чикләрендә мондый хокук бозуларны булдырмау чараларын күрә, шулай ук 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә юридик затка, индивидуаль эшкуарга планнан тыш тикшерүне билгеләү турында карар кабул итү өчен ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүматны язма рәвештә җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә җиткерә.

Планлы яисә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яисә башка вазыйфаи заты булмаганга күрә мөмкин булмаган очракта, яисә юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлеген чынлыкта башкармауга бәйле рәвештә яки индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең яисә юридик затның башка вазыйфаи затының бүтән гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән бәйле

рәвештә тикшерү үткәрү мөмкин булмау килеп туганда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты, аны үткәрүнең мөмкин булмавын күрсәтеп, тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзи. Бу очракта дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән алып өч ай эчендә мондый юридик затка, индивидуаль эшкуарга планлы яисә планнан тыш күчмә тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә генә һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр итмичә генә аларга карата тикшерү уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

Муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи затлары административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган хокук бозулар өчен юридик һәм вазыйфаи затларга, гражданнарга карата (җирлекнең Татарстан Республикасы законнарында каралган җирле үзидарә органнары вәкаләтләре кысаларында) беркетмәләр төзи һәм алар тикшерү төгәлләнгәннән соң компетенцияләрендә закон нигезендә затны юридик җаваплылыкка тарту каралган дәүләт контроле (күзәтчелек) органына яисә дәүләт хакимиятенең башка органына җибәрелә.

Административ процедураны башкару срогы – 3 эш көненнән артык түгел.

## 4. Контроль тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Муниципаль контрольнең үтәлешен контрольдә тоту авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан агымдагы контроль һәм планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.2.Агымдагы контроль төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан административ процедураларны үтәү тәртибен билгеләүче норматив хокукый актлар нигезләмәләрен һәм методик рекомендацияләрне үтәүне һәм башкаруны тикшерү, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерү, карау, мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатенә карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.3.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы тикшерүләре елга кимендә бер мәртәбә уздырыла. Планнан тыш тикшерүләр муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләре кергәндә, шулай ук җирлекнең Башкарма комитеты йөкләмәсе (кушуы) буенча үткәрелә.

4.4.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга җаваплы вәкаләтле вазыйфаи зат әлеге Административ регламентта күрсәтелгән һәр административ процедураны башкару сроклары һәм тәртибе өчен, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителә торган барлык гамәлләр (гамәл кылмаулар) һәм (яисә) карарлар өчен җаваплы.

4.5.Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга контроль Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә җирлек Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырылган тиешле мәгълүматтан файдаланып, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә гамәлгә ашырыла.

## 5.Муниципаль хезмәтләр күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы муниципаль контроль органы, шулай ук аның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1.Кызыксынучы затлар муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга шикаятьне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә белдерергә хокуклы. Әлеге административ регламент нигезендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында муниципаль контроль органы вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр (гамәл кылмау) һәм карарлар судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы

булырга мөмкин.

5.2. Шикаятьне карауны туктатып тору өчен нигезләрнең һәм шикаятькә җавап бирелми торган очракларның тулы исемлеге

5.2.1.Шикаятьне карауны туктатып тору өчен нигезләр юк.

5.2.2. Шикаятькә җавап бирелмәү очраклары исемлеге:

1) цензурасыз яисә мыскыллы әйтелмәләр булган, вазыйфаи затның тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар (шулай ук аның гаилә әгъзаларына) булган язма мөрәҗәгать (шикаять) алганда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитеты мөрәҗәгатьне анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгать җибәргән кызыксынучы затка хокуктан явызларча файдалануның ярамавы турында хәбәр итәргә хокуклы;

2) язма мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) җавап җибәрелергә тиешле гражданның фамилиясе яисә почта адресы күрсәтелмәгән очракта;

3) язма мөрәҗәгать (шикаять) текстын укырга мөмкин булмаса, мөрәҗәгать (шикаять) каралырга тиеш түгел, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы танылса, мөрәҗәгатьне җибәргән кызыксынган затка бу хакта хәбәр ителә;

4) суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгать, әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать (шикаять) җибәргән кызыксынган затка кире кайтарыла;

5) кызыксынган затның мөрәҗәгатендә (шикаятьендә) аңа элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә (шикаятьләргә) бәйле рәвештә асылда берничә тапкыр язма рәвештә җаваплар бирелгән һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) яңа дәлилләр яисә шартлар китерелми торган мәсьәлә булса, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге мәсьәлә буенча чираттагы мөрәҗәгатьнең (шикаятьнең) нигезсез булуы һәм язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы, күрсәтелгән мөрәҗәгать (шикаятьнең) һәм элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләрнең (шикаятьләрнең) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетына юлланган булу шарты белән;

6) мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) куелган сорауның асылы буенча җавап федераль закон белән саклана торган дәүләт яисә башка серне тәшкил итүче мәгълүматларны ачыкламыйча гына бирелә алмаса, мөрәҗәгать юллаган кызыксынган затка күрсәтелгән мәгълүматларны таратуның ярамаганлыгына бәйле рәвештә анда куелган сорауның асылына җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелмәгән сәбәпләр алга таба бетерелгән очракта, кызыксынучы зат мөрәҗәгатьне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетына яңадан җибәрергә хокуклы;

7) язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта (мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә);

8) җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җавабы 2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган язма мөрәҗәгать кергән очракта (мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн эчендә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, анда мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган, шул ук вакытта суд карарына шикаять белдергән мөрәҗәгать кире кайтарылмый).

5.3. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигезләр

5.3.1. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен кызыксынган зат тарафыннан язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон рәвештә шикаять бирү нигез булып тора.

5.3.2.Шикаятьләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетына тапшырыла яисә почта юлламасы белән почта аркылы әлеге Административ регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән адрес буенча яки электрон документ рәвешендә әлеге Административ регламентның 2.1

пунктында күрсәтелгән электрон почта адресы буенча җибәрелә.

5.4. Шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга кызыксынучы затларның хокуклары

5.4.1. Кызыксынган зат шикаятьне нигезләү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны ул башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаганда һәм күрсәтелгән документларның Россия Федерациясе законы белән саклана торган дәүләт серен һәм башка серне тәшкил итүче мәгълүматлары булмаган очракта алырга хокуклы.

5.5.Шикаятьне карау сроклары

5.5.1. Шикаять аны теркәгәннән соң 30 көн эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда, шулай ук гарызнамәне дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәргән очракта, шикаятьне карау срогы 30 көннән дә артмыйча озайтылырга мөмкин, бу хакта шикаятьне биргән затка, озайту сәбәпләрен күрсәтеп, язма рәвештә хәбәр ителә.

5.6.Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәләре

5.6.1. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә:

1) Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән муниципаль контроль органы вазыйфаи затының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) һәм (яисә) карарларын дөрес дип тану һәм шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында;

2) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда кабул ителгән муниципаль контроль органы вазыйфаи затының гамәлләрен (гамәл кылмавын) һәм (яисә) карарын дөрес түгел дип тану һәм җибәрелгән хокук бозуларны бетерү максатларында муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе законнарында каралган әлеге Административ регламент нигезендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кылган гамәле (гамәл кылмавы) һәм гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) карары өчен һәм кызыксынган затның шикаятенә китергән муниципаль контроль органы вазыйфаи затына карата җаваплылык чаралары билгеләү турында.

5.6.2.Кызыксынган затка кабул ителгән карар һәм кабул ителгән карар нигезендә башкарылган гамәлләр турында хәбәрнамә җибәрелә.

5.6.3. Муниципаль контроль органының конкрет вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять биргән кызыксынган затның мөрәҗәгатьләре әлеге вазыйфаи затларга карау һәм (яки) җавап бирү өчен җибәрелә алмый.